Олыяз авыл җирлеге Советы

**КАРАР**

10 июнь 2024 ел № 21

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 бүлекнең 19 пункты, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставы нигезендә Олыяз авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 29 ноябрендәге 33 номерлы Олыяз авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы Р.Ф.Маликов

Олыяз авыл җирлеге Советының 10.06.2024 ел
№ 21 карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибен билгели (алга таба – төзекләндерү өлкәсендә контроль).

1.2. Төзекләндерү өлкәсендә контроль предметы булып юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның (алга таба – контрольдә тотыла торган затлар)Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен (алга таба – төзекләндерү кагыйдәләрен), инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен (алга таба шулай ук – мәҗбүри таләпләр) үтәү тора.

1.3. Төзекләндерү өлкәсендә контроль Олыяз авыл башкарма комитеты (алга таба – администрация) тарафыннан башкарыла.

1.4. Администрациянең төзекләндерү өлкәсендә контроль алып барырга вәкаләтле вазыйфаи затлары – Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы (башлык урынбасары) һәм Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре (алга таба шулай ук – контроль алып барырга вәкаләтле вазыйфаи затлар). Администрациянең күрсәтелгән вазыйфаи затларының вазыйфа бурычларына аларның вазыйфа инструкциясе нигезендә төзекләндерү өлкәсендә контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыру керә.

Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә Төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәргәндә контроль алып барырга вәкаләтле вазыйфаи затларның хокуклары, бурычлары бар һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә җаваплылык тоталар.

1.5. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру, профилактик чаралар, контроль чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

1.6. Администрация төзекләндерү Кагыйдәләренең үтәлешен контрольдә тота, шул исәптән:

1) янәшәдәге территорияләрне карап тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

2) төзекләндерү элементлары һәм объектларын тоту буенча мәҗбүри таләпләр, шул исәптән таләпләр:

- халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, физик культура һәм спорт, халыкка социаль хезмәт күрсәтү объектларына иркле керүенә комачауламый торган коймалар урнаштыру буенча;

- торак булмаган биналар, корылмалар, төзелмәләрнең фасадларын, биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең башка стеналарын, шулай ук төзекләндерүнең башка элементларын һәм җәмәгать урыннарын карап тоту буенча;

- инженерлык корылмаларын эксплуатацияләү өчен кирәкле мәгълүматны үз эченә алган махсус билгеләр, язуларны тоту буенча;

- җир эшләре башкарылган чорда биналарга һәм аларга керү урыннарына иркле юллар, шулай ук ишегалларына иркле керү юлларын тәэмин итү, җәяүлеләр, шул исәптән инвалидлар

һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре иминлеген һәм җәяүлеләр хәрәкәтенең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча;

- Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнгән срокта аварияләр нәтиҗәсендә килеп туган эшләр башкару турында администрациягә хәбәрнамә җибәрү буенча;

- транспорт чараларын газонга яки башка яшелләндерелгән территориягә, яки төзекләндерү кагыйдәләре белән анда транспорт чараларын урнаштыру чикләнгән рекреацион территориягә урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында, шулай ук аларны эксплуатацияләү, хезмәт күрсәтү яки ремонтлау вакытында, йөкләр ташу яки төзелеш мәйданчыкларыннан чыгу вакытында (тент яки япма булмау сәбәпле) гомуми файдаланудагы территорияләрне транспорт чаралары белән пычрату рөхсәт ителмәве турында;

3) Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясен кышкы чорда җыештыру буенча, шул исәптән биналарның, корылмаларның түбәләрен кардан, боздан һәм боз сөңгеләреннән чистарту буенча чаралар үткәрүне контрольдә тоту буенча мәҗбүри таләпләр

4) Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясен җәйге чорда җыештыру буенча, шул исәптән карантин, агулы һәм чүп үләннәрен ачыклау, алар белән көрәшү, аларның күпләп үскән урынын билгеләү, бетерү буенча мәҗбүри таләпләрне дә кертеп, мәҗбүри таләпләр;

5) махсус янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычсызлыгының өстәмә мәҗбүри таләпләре;

6) гомуми файдаланудагы территорияләрдә җир асты коммуникацияләрен салу, үзгәртеп кору, ремонтлау һәм тоту буенча мәҗбүри таләпләр;

7) каты коммуналь калдыкларны саклау буенча мәҗбүри таләпләр;

8) хайваннарны йөртү буенча мәҗбүри таләпләр һәм авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын гомуми файдаланудагы территорияләрдә һәм төзекләндерү кагыйдәләрендә каралган башка территорияләрдә көтүгә юл куймау турында таләпләр.

Администрация контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан аларның компетенциясе чикләрендә бирелгән мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең үтәлешен контрольдә тота.

1.7. Әлеге Нигезләмәдә төзекләндерү элементлары дип декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, төрле җиһазлау һәм бизәү төрләре, шул исәптән биналар, корылмалар, төзелмәләр фасадларын да, кече архитектура формалары, капиталь булмаган стационар булмаган корылмалар һәм төзелмәләр, территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла торган мәгълүмати щитлар һәм күрсәткечләр аңлашыла.

Әлеге Нигезләмәдә төзекләндерү объектлары дип төзекләндерү буенча эшчәнлек алып барыла торган төрле функциональ билгеләнештәге территорияләр аңлашыла, шул исәптән:

1) планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исәптән торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сәнәгать районнары, яр буйлары), гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек коммерцияле булмаган берләшмәләре урнашкан территорияләр);

2) урам-юл челтәре элементлары (аллеялар, бульварлар, магистральләр, тыкрыклар, мәйданнар, керү юллары, проспектлар, кечкенә урамнар, разъездлар, төшү юллары, трактлар, тупиклар, урамнар, шоссе);

3) ишегалды территорияләре;

4) балалар һәм спорт мәйданчыклары;

5) хайваннарны йөртү мәйданчыклары;

6) парковкалар (машина кую урыннары);

7) парклар, скверлар, башка яшел зоналар;

8) техник һәм санитар-саклау зоналары;

Әлеге Нигезләмәдәге саклагыч җайланмалар дип капкалар, кече капкалар, шлагбаумнар, шул исәптән автоматлары шлагбаумнар һәм декоратив коймалар (киртәләр) аңлашыла.

1.8. Администрация төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру кысаларында төзекләндерү өлкәсендә контроль объектларын исәпкә алуны тәэмин итә.

Администрация тарафыннан төзекләндерү өлкәсендәге контроль объектларын әлеге Нигезләмә нигезендә билгеле бер куркыныч категориясенә кертү гамәлгә ашырыла.

## 2. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар китерү) куркынычлары белән идарә итү

2.1. Администрация төзекләндерү өлкәсендә зыян китерү (зарар китерү) куркынычлары белән идарә итү нигезендә контроль алып бара.

2.2. Төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәргәндә закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын идарә итү максатларында әлеге Нигезләмәнең 1.7 пунктында каралган мондый контроль объектлары «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә куркыныч категорияләренә кертелергә тиеш.

2.3. Администрация тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә әлеге Нигезләмәнең 1.7 пунктында каралган контроль объектларын (алга таба – контроль объектлары) билгеле бер куркыныч категориясенә кертү әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашырганда тиешле объектларны билгеле бер куркыныч категориясенә кертү критерийлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү һәм контроль объектларына бирелгән куркыныч категорияләрен үзгәртү администрация боерыгы белән башкарыла.

Администрация тарафыннан контроль объектларын куркыныч категорияләренә керткәндә шул исәптән түбәндәгеләр кулланыла:

1) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы мәгълүматлар;

2) контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан контрольдә тотылган затлар белән аралашмыйча контроль үткәргәндә алына торган мәгълүматлар;

3) администрациядәге башка мәгълүматлар.

2.4. Администрация тарафыннан бирелгән куркыныч категориясенә бәйле рәвештә планлы контроль чаралар үткәрү түбәндәге вакыт аралыгы белән башкарыла:

1) югары куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектлар өчен – 2 елга бер тапкыр;

2) уртача куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен – 3 елга бер тапкыр.

Түбән куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектларына карата планлы контроль чаралары үткәрелми.

Контроль объектларын түбән куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул итү таләп ителми.

2.5. Еллык планлы контроль чаралар планнарына еллык планны гамәлгә ашыру елында түбәндәге куркыныч категориясенә кертелгән контроль объектлары өчен соңгы планлы контроль чарасы тәмамланганнан алып вакыт чоры бетә торган контроль объектларына карата контроль чаралар кертелергә тиеш:

1) югары куркыныч, – ким дигәндә 2 ел;

2) уртача куркыныч, – ким дигәндә 3 ел.

Әгәр элек контроль объектларына карата планлы контроль чаралар үткәрелмәгән булса, еллык планга контроль объектлары юридик затның яки гражданның контроль объектына милек хокукы барлыкка килгән көннән соң бер ел узгач, ә янәшәдәге территорияләр белән булган очракта – Төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә янәшәдәге территорияне карап тоту буенча бурыч барлыкка килгән көннән кертелергә тиеш.

2.6. Контроль объектының хокук иясе соравы буенча, сорау килгәннән соң 15 көннән дә артмаган вакытта контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар сорау килгәннән соң 15 көннән дә артмаган вакыт эчендә аңа контроль объектына бирелгән куркыныч категориясе турында мәгълүмат, шулай ук мондый объектны билгеле бер куркыныч категориясенә керткәндә кулланылган мәгълүматны бирәләр.

Контроль объектының хокук иясе администрациягә контроль объектына элек бирелгән куркыныч категориясен үзгәртү турында гариза бирергә хокуклы.

2.7. Администрация куркыныч категорияләре бирелгән контроль объектлары исемлеген алып бара (алга таба – контроль объектлары исемлеге). Контроль объектларын контроль

объектлары исемлегенә кертү әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән Администрация боерыгы нигезендә башкарыла.

Риск категорияләре күрсәтелгән контроль объектлары исемлеге «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (алга таба – администрациянең рәсми сайты) контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә урнаштырыла. Махсус бүлеккә керү рәсми сайтның баш (төп) битеннән башкарылырга тиеш.

2.8. Контроль объектлары исемлегендә түбәндәге мәгълүмат була:

1) контроль объектын идентификацияли торган мәгълүмат (контроль объектының урнашкан урыны адресы, кадастр номеры (әгәр булса), контроль объектын идентификацияли торган башка билгеләр (кирәк булганда));

2) бирелгән куркыныч категориясе;

3) контроль объектына куркыныч категориясен бирү турында карар реквизитлары.

## 3. Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау

3.1. Администрация төзекләндерү өлкәсендә контрольне профилактик чаралар үткәрү аша да гамәлгә ашыра.

3.2. Профилактик чаралар контрольдә тотыла торган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намус белән үтәүне стимуллаштыру, мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яки) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүгә китерә алган шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү, мәҗбүри таләпләрне, аларны үтәү ысулларын контрольдә тотыла торган затларга җиткерү максатларында администрация тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.3. Төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәргәндә зыян (зарар) китерү куркынычын киметүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү контроль чаралар үткәрүгә карата өстенлекле булып тора.

3.4. Профилактика чаралары Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау программасы нигезендә гамәлгә ашырыла, шулай ук зыян китерү куркынычларын профилактикалау программасында каралмаган профилактик чаралар да үткәрелергә мөмкин.

Профилактик чаралар үткәргәндә контроль объектларының закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерүнең турыдан-туры куркынычы булып торуы яки мондый зыян (зарар) китерелгәне ачыкланган очракта, контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи зат, контроль чаралар үткәрү турында карар кабул итү өчен, шунда ук Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгына (башлык урынбасарына) мәгълүмат җибәрә.

3.5. Администрация тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә контроль үткәргәндә түбәндәге профилактика чаралары үткәрелергә мөмкин:

1) мәгълүмат бирү;

2) хокукны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү;

3) кисәтүләр игълан итү;

4) консультация бирү;

5) профилактик визит.

3.6. Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат администрация тарафыннан тиешле белешмәләрне рәсми сайттагы контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә, массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән, контроль үткәрелә торган затларның дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетлары аша (алар булганда) һәм башка рәвешләрдә башкарыла.

Администрациянең рәсми сайтында контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясының 3 өлешендә каралган мәгълүматларны урнаштырырга һәм актуаль хәлдә тотарга тиеш.

Администрация шулай ук Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге халкына гражданнарның җыелышларында һәм конференцияләрендә контроль объектларына куелган

мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч критерийларына туры килүе, шулай ук контроль объектларына карата үткәрелә торган контроль чараларның төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында хәбәр итәргә хокуклы.

3.7. Хокукны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү үткәрелгән контроль чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүматны җыю һәм анализлау аша администрация тарафыннан башкарыла.

Хокукны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча, контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар ел саен төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру буенча хокукны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү нәтиҗәләрен үз эченә алган һәм администрация башлыгы имзалаган, администрация боерыгы белән расланган доклад әзерли. Әлеге доклад хисап елыннан соң киләсе елның 1 июленә кадәр администрациянең рәсми сайтында контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә урнаштырыла.

3.8. Мәҗбүри таләпләрне бозуны рөхсәт итмәү турында кисәтү һәм мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрү тәкъдиме администрациядә әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозу яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр булган очракта һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозу закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүе яисә закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычы тудыруы турында расланган белешмәләр булмаган очракта, контроль үткәрелә торган затка игълан ителә. Кисәтүләр Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан күрсәтелгән мәгълүматларны алганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча игълан ителә (имзалана). Кисәтү язма яки электрон документ формасында әзерләнә һәм контроль үткәрелә торган зат адресына җибәрелә.

Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типовой формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән расланган форма нигезендә рәсмиләштерелә.

Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр теркәлү номеры белән кисәтүләрне исәпкә алу журналында теркәлә.

Администрация тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуны рөхсәт итмәү турында кисәтү игълан ителгән очракта, контроль үткәрелә торган зат күрсәтелгән кисәтүгә каршы гариза бирергә хокуклы. Кисәтүгә каршылык администрация тарафыннан алынган көннән алып 30 көн эчендә карала. Каршылыкны карау нәтиҗәсендә контроль үткәрелә торган кешегә язмача яки электрон документ формасында каршылык белән килешү яки риза булмау турында мәгълүмат белән җавап җибәрелә. Каршылык белән риза булмаган очракта, җавапта тиешле нигезләмәләр күрсәтелә.

3.9. Контроль үткәрелә торган затларга консультацияне контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан телефон аша, видео-конференц-элемтә аша, шәхси кабул итү вакытында яки профилактик чаралар, контроль чаралар үткәрү барышында гамәлгә ашырыла һәм 15 минуттан артмаска тиеш.

Гражданнарны шәхси кабул итүне Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы (башлык урынбасары) һәм (яки) контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи зат үткәрә. Кабул итү урыны, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат администрациянең рәсми сайтында контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә урнаштырыла.

Консультация телдән яки язма формада түбәндәге мәсьәләләр буенча башкарыла:

1) төзекләндерү өлкәсендә контроль оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән контроль чараларны гамәлгә ашыру тәртибе;

3) контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тәртибе;

г) үтәлешләрен бәяләү администрация тарафыннан контроль чаралар кысаларында гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар (аларның аерым нигезләмәләре) турында мәгълүмат алу.

Контрольдә тотылган затларга телдән консультация бирү шулай ук гражданнар җыеннарында һәм конференцияләрендә дә башкарыла ала.

3.10. Контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан язма рәвештә консультация бирү түбәндәге очракларда башкарыла:

1) контроль үткәрелә торган зат тарафыннан консультация мәсьәләләре буенча язмача җавап бирү турында язмача сорату бирлегән;

2) консультация вакытында бирелгән сорауларга телдән җавап бирү мөмкин түгел;

3) куелган сорауларга җавап бирү өстәмә мәгълүмат соратып алуны таләп итә.

Консультация биргәндә контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат Россия Федерациясе законнары нигезендә керү мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген үтәргә тиеш.

Консультация барышында конкрет контроль чараны, контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларның, контроль чарада башка катнашучыларның карарларын һәм (яки) гамәлләрен, шулай ук контроль чара кысаларында үткәрелгән экспертиза, сынау нәтиҗәләрен бәяләүне үз эченә алган мәгълүмат бирелә алмый.

Консультация барышында контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затка билгеле булган мәгълүмат администрация тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча контроль үткәрелә торган затны бәяләү максатларында кулланыла алмый.

Контрольне башкарырга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан консультацияләрне исәпкә алу журналы алып барыла.

Контроль үткәрелә торган затларның һәм аларның вәкилләренең администрациягә биш һәм аннан да күбрәк бертөрле мөрәҗәгатьләре кергән очракта, консультацияләр администрациянең рәсми сайтында контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы (башлык урынбасары) яки контроль үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган язма аңлатма урнаштыру юлы белән башкарыла.

3.11. Профилактик визит контроль үткәрелә торган затның эшчәнлек алып бару урынында профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференц-элемтәдән файдалану юлы белән үткәрелә.

Профилактика визиты барышында контроль үткәрелә торган затка аның эшчәнлегенә йә аңа караган контроль объектларына карата куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның риск критерийларына туры килүе, риск категориясен киметүнең нигезләре һәм тәкъдим ителгән ысуллары, шулай ук, аларны тиешле риск категориясенә кертүдән чыгып, контроль объектларына карата, үткәрелә торган контроль чараларның төрләре, эчтәлеге һәм интенсивлыгы турында хәбәр ителә.

Профилактик визит үткәргәндә, контроль үткәрелә торган затларга мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында күрсәтмәләр бирелми. Контроль үткәрелә торган затка профилактик визит барышында бирелгән аңлатмалар тәкъдим итү характерында.

Мәҗбүри профилактик визит югары куркыныч категориясенә караган контроль объектларына карата эшчәнлекне гамәлгә ашыруга керешүче контроль үткәрелә торган затларга карата үткәрелә.

Мәҗбүри профилактика визиты үткәрү турында контроль үткәрелә торган затка аны үткәрү датасына кадәр кимендә биш эш көненнән дә соңга калмыйча контроль үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан хәбәр ителә.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә язма рәвештә төзелә.

Мәҗбүри профилактик визит үткәрү турында хәбәрнамә контроль үткәрелә торган зат адресына «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 21 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

Контроль үткәрелә торган зат, бу хакта администрациягә аны үткәрү датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итеп, мәҗбүри профилактика визиты уздырудан баш тартырга хокуклы.

Мәҗбүри профилактик визитны үткәрү вакыты контроль алып барырга вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан билгеләнә һәм бер эш көненнән артмаска тиеш.

Контрольдә тотыла торган зат контроль органына аңа карата профилактик визит үткәрү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы (алга таба – шулай ук контрольдә тотыла торган затның гаризасы).

Контроль органы әлеге гаризаны теркәгән көннән алып ун эш көне дәвамында контрольдә тотыла торган затның гаризасын карый һәм профилактик визит үткәрү турында карар кабул итә, яисә контрольдә тотылган зат хәбәр иткән контроль органның матди, финанс һәм кадрлар ресурсларын, контроль объектының куркыныч категориясен исәпкә алып, профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Контроль органы түбәндәге нигезләрнең берсе буенча контрольдә тотыла торган затның гаризасы буенча профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итә:

1) контрольдә тотыла торган заттан профилактик визит үткәрү турындагы гаризаны кире алуы турында хәбәр килгән;

2) контрольдә тотыла торган затның гаризасын тапшырган көнгә кадәр ике ай дәвамында контроль органы тарафыннан әлеге контрольдә тотыла торган затка карата профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителгән;

3) контрольдә тотыла торган зат гариза биргән көнгә кадәр алты ай дәвамында профилактик визит үткәрү контрольдә тотыла торган затның эшчәнлек урынында булмавы якиконтрольдә тотыла торган затның башка гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында профилактик визит үткәрү мөмкин булмау сәбәпле мөмкин булмаган;

4) контрольдә тотылган затның гаризасында әдәпсез яки мыскыллаучы сүзләр, (күзәтчелек) органы вазыйфаи затларының яки аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә куркынычлар бар.

Контрольдә тотыла торган затның гаризасы буенча профилактик визит үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, контроль органы егерме эш көне дәвамында мондый килешүне теркәүне тәэмин итүче теләсә нинди ысул белән контрольдә тотылган зат белән профилактик визит үткәрү датасын килештерә һәм мондый профилактик визитны закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар китерү) куркынычларын профилактикалау программасына кертүне тәэмин итә.

## 4. Контроль чараларны һәм контроль гамәлләрне гамәлгә ашыру

4.1. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда администрация тарафыннан күрсәтелгән чаралар кысаларында түбәндәге контроль чаралар һәм контроль гамәлләр үткәрелергә мөмкин:

1) инспекция визиты (мәҗбүри таләпләргә ярашлы рәвештә контрольдә тотыла торган зат (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерым структур бүлекчәләре) урнашкан урында булырга тиешле документларны карап тикшерү, сораштыру, документлар таләп итү, язма аңлатмалар алу, инструменталь тикшерү аша);

2) рейд тикшерүе (карап тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза аша);

3) документар тикшерү (язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, экспертиза аша);

4) күчмә тикшерү (карап тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар таләп итү, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза аша);

5) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (төзекләндерү өлкәсендә контроль объектлары турында мәгълүмат җыю һәм анализлау аша, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында килә, мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында контроль үткәрелә торган затлар тарафыннан бирелә торган мәгълүматлар, шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларында булган мәгълүматлар, «Интернет» челтәреннән алынган мәгълүматлар, башка гомуми кулланышта булган мәгълүматлар, шулай ук автомат режимда эшли торган хокук бозуларны теркәүнең фото- һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган техник чараларын кулланып алынган мәгълүматлар аша)

6) күчмә карап тикшерү (тикшереп карау, инструменталь тикшерү (видеоязма кулланып), сынау, экспертиза аша).

